

Ромодан районы ОАО АПО «Элеком» авыл хужалыгы бvлегендә чын-чыннан тырышып хезмәт иткән кешеләр байтак. Алар арасында Алтар авылында туып-vскән, гомер итә торган Менир Хафиз улы Ипкаев механизатор булып эшли. Анын эш стажы кырык елга житә. Һәрбер эшне жиренә житкереп эшләргә яраткан Менир Хафиз улынын Хормәт грамоталары, Рәхмәт хатлары аз тvгел. Барысы да унышлы нәтижәләре очен! - Он у нас хороший специалист, ответственный. С таким работать надежно и спокойно. Самые сложные участки всегда его, потому как он не подведёт. На его примере учим молодёжь, как относиться к технике. Одним словом, Менир Хафизович пользуется большим уважением, - чын кvнелдән мактау сvзләрен коллегалары әйтә. - Вот уж поистине не зря в народе говорят: «Какую жизнь проживёшь, такую и славу наживёшь».

Тыйнак кына vзе турында механизатор менә нәрсә ди: «Әтием Хафиз гомере буе тракторист булып эшләде. Ә мин яшvсмер чагымда ана еш кына ярдәм итә торган идем. Ул мине әкрен генә механизаторлык профессиясенә алып килде дә инде. Аннары - армия; хәрби хезмәттән сон кулымда трактористлыкка праваларым бар иде инде. Алтар авылы колхозыбыз иген-кырларында берvзем генә эшли башладым: яз башында һәм жәй-коз коннәрендә жир сукаладым, чәчтем - топ эшләрем шул булды, ә кыш коне бульдозерга утыра идем, - ди Менир Хафизович. Елмаеп сvзен дәвам итте: кvбрәк кырда эшләргә яратам. Иксез-чиксез кырлар буенча бараганда жир белән кvк тоташкан горизонт чикләренен матурлыгына сокланып туймыйсын».

Язма героебыз тормышында тәртип: эштә дә, оендә дә. Тормыш иптәше белән ике малай тәрбияләп vстерәләр. Бvген аларнын дvрт оныклары тормышларына ямь ости. Һәр ял коне зур остәл артында берничә буын кешеләре рәхәтләнеп аралашалар. Хатын-кызлар милли ашлар әзерләсә, ир-атлар хужалыкта эшлиләр. Пәрәмәч, бәлешле һәм алкалы чәйне эчкәч, бабакайлары оныкларына мавыктыргыч итеп хезмәт биографиясеннән ин кызыклы чакларын сойли. Шулай тормышта жиде буын бәйләнә.

- Профессональ унышка тиз генә ирешеп булмый, анын очен кvп кенә тырышлык һәм vз эшенә чын-чыннан бирелгәнлек кирәк. Крестьян хезмәте жинелләрдән тvгел, әмма бу минем сайлаган юлым. Шуна жир-анабызга жанын-тәнен белән тырышып эшләргә кирәк», - дип фикер йортә Менир Хафиз улы Ипкаев. Анын Алтар туган авылыннан шәһәргә беркайчан чыгып китәсе килмәгән. Авылны ярата ул. Туган жир кырларында эшли, ә жире аны ашата.

**Н.Хәлил**